Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Советы Карары

«17» май 2021 ел № 26

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018елның 15 декаберендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 29.12.2017 ел, № 463-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 85 номерлы карары нигезендә расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына 1 нче номерлы кушымта нигезендэ үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гәрәев Х.Х.

Совет Кулле-Киминского сельского поселения
Күлле-Киме авыл җирлеге советы

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Советының
2021 елның «17» мае № 26 номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 15 декаберендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 85 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**12 статьяның 3 абзацын түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:**

« җирлекнең генераль планына, шәһәр округының Генераль планына үзгәрешләр әзерләү очракларыннан тыш, территорияне комплексլы үстерү турында Карар кабул ителү белән бәйле җәмәгать тыңлаулары яисә гавами тыңлаулар, аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин».